Исполнительный комитет
Камаевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан

423643,РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
башкарма комитеты

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай урамы
29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

От 2019 ел 24 нче декабрь № 25

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Камай авыл җирлегендә Яңа ел
бәйрәмнәренә әзерлек һәм үткәрү
чорында янгын куркынычсызлыгын
тәэмин итү турында

Камай авыл җирлегендә Яңа ел бәйрәмнәренә әзерлек һәм үткәрү чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. 20.12.2019 елдан 20.01.2020 елга кадәр Камай авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.
2. Камай авыл җирлеге территориясендә Яңа Ел бәйрәмнәрен үткәрү чорында янгын куркынычсызлыгы буенча комиссия составын расларга:
   Комиссия рәисе :

И. И. Әһлиева - Камай авыл җирлеге башлыгы

Члены комиссии:

Комиссия әгъзалары:

Иванова А. Ш. – Камай мәктәбе директоры;

Аннамурадова Р. Б.- балалар бакчасы мөдире;

Аглиева Э. Г. – Камай мәдәният йорты директоры;

Рахимова Л.Н. – Камай авыл мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе;

Галимуллина Г. М.- Камай авылы китапханәчесе ;

Калимуллин Р. Р. – ДНД командиры;

Әһлиев Д. Р.- Камайагро авыл хуҗалыгы кооперативы башлыгы;

Хәйриев И. Р. – “ Хәйриев И.Р.” КФХ гы башлыгы

Зиннатуллина Г. М. – Камай авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибы

3. Мәдәният һәм мәгариф, сәламәтлек саклау һәм сәүдә учреждениеләре җитәкчеләренә:

- Яңа ел бәйрәм чараларына әзерлек һәм аларны уздыру чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар комплексын тормышка ашырырга (беренчел янгын сүндерү чаралары, эвакуация чыгу юллары, автоматик янгын сигнализациясе, электр үткәргечләр (сүндергечләр, розеткалар) һәм башкалар.)

- биналарны бизәгәндә бары тик сертификацияләнгән электр гирляндалары, иллюминацияләр һәм башка бәйрәм атрибутларын гына кулланырга ;

- кышкы чорда юлларны, объектларга керү юлларын вакытында кардан һәм боздан чистартуны оештырырга;

- балалар өчен яңа ел чыршыларын, Яңа ел кичәләрен оешкан төстә үткәрүне тәэмин итәргә;.

4. Камай авыл җирлеге территориясендә күпләп һәм ваклап сату белән шөгыльләнүче предприятиеләр җитәкчеләренә:

- законда билгеләнгән сертификатлары булмаган, техник документларда аларның янгын куркынычсызлыгы күрсәткечләре һәм алар белән мөрәҗәгать иткәндә янгын куркынычсызлыгы чаралары күрсәтелмәгән пиротехник эшләнмәләр һәм электр гирляндалары, шулай ук Яңа ел бизәү әйберләре, ясалма чыршылар сатуны булдырмау буенча чаралар күрергә.

5. Урамда куелган чыршылары бизәгәндә сертификацияләнгән электр гирляндалары кулланырга.

6. Кышкы чорда янгын гидрантларын, торак пунктларга, объектларга, торак йортларга илтүче юлларны һәм янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларын кардан һәм боздан үз вакытында чистарту эшләрен оештырырга.

7. Янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

8. Янгын куркынычсызлыгы өчен учреждениеләр җитәкчеләренә, КФХ башлыкларына һәм торак йортларның милекчеләренә җаваплылык йөкләргә.

9. Бәйрәм көннәре һәм ял көннәрендә ДНД командирына график буенча патрульлек итүне оештырырга .

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Камай авыл җирлеге башлыгы И.И.Әһлиева